ПРОЕКТ ЭШЕ

# УКЫЛГАН ТЕКСТКА НИГЕЗЛӘНЕП СОЧИНЕНИЕ ЯЗУ

Башкардылар: А.Н.Гыйлаҗиева
Казан шәһәре Совет районының 126нчы гимназиясе

## Актуальлеге:

Татарстан Республикасындагы рус телендә гомуми урта белем бирү мәктәпләрендәге татар төркемнәрендә белем алучы 9 сыйныф укучыларын бердәм республикасы тесты үтү вакытында башкарыла торган иҗади биремгә әзерләү

## Максаты:

укучыларны укылган текстка нигезләнеп, сочинение-фикерләмә язарга өйрәтү

## Бурычлары:

1) укучыларны сочинение-фикерләмә язу кагыйдәләре белән таныштыру;

2) укучыларда укылган текстка нигезләнеп, сочинение-фикерләмә язу күнекмәләре булдыру;

## Көтелгән нәтиҗә:

укучыларның сочинение-фикерләмәнең төзелешен дөрес күзаллауга ирешү;
укучыларның,  укылган текстка нигезләнеп, язылган сочинение-фикерләмәләрендә автор фикерен табу һәм аңа үз фикерләрен җиткерүне булдыру;
укучыларның орфографик сүзлектән файдалана һәм сочинениене грамоталы яза белүенә ирешү.

# СОЧИНЕНИЕ-ФИКЕРЛӘМӘ ЯЗУДА ИГЪТИБАР ЮНӘЛТЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ТӨП МОМЕНТЛАР

1. Укылган текстның мәгънәсен дөрес аңлау
2. Автор фикерен дәлилләүче мисалларны тексттан таба белү
3. Сочинениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелегенә ирешү
4. Сочинениенең компазицион төзеклеге

# Язманың грамоталы бирелешенә ирешү

1.Орфографик нормаларның үтәлү критерие

2.Пунктуация нормаларының үтәлеше.

3.Грамматик нормаларның үтәлеше.

4.Сөйләм нормаларының үтәлеше

5.Язма сөйләмнең тӧгәллеге критерие  терминнарны урынлы  кулланыны һәм фактик хаталар булу булмауны бәяли.

Сочинение – фикерләмә язу укучылар өчен катлаулы бирем. Аны барлык укучылар да тиешле рәвештә дөрес итеп үти алмыйлар, чөнки алар дәрестә эшли торган биремнәрдән бик нык аерылалар, мәктәп дәреслекләрендә бу төр биремнәргә урын бирелми. Шунлыктан без – укытучыларның төп бурычы – укучыларга күрсәтмә бирү, эш алымнарын өйрәтү.

Ә моның өчен тикшерү критерийларын яхшы күзаллау, укучыларның игътибарын шуларга юнәлтү кирәк. Дәресләрдә даими рәвештә мондый төр күнекмәләр булдыру укучыларны сочинение – фикерләмә язганда кыен хәлдә калудан коткарачак, аларның эш нәтиҗәләре яхшы булачак.

# КУШЫМТА
# УКУЧЫЛАР ЯЗГАН СОЧИНЕНИЕ-ФИКЕРЛӘМӘ ҮРНӘКЛӘРЕ



Текст „Ә бүре беркемгә дә ялагайланмый, ярарга тырышмый. Бәлки кеше шуңа күрә дә аны дошман күрәдер" – дип тәмамлана. Мин автор сүзләре белән килешәм. Чыннан да, бүреләр беркемгә дә буйсынмыйлар. Алар үзләре теләгәнчә генә яшәп йөриләр.

Менә, мәсәлән, әти бирелгән өзектә (7) җөмләдә бүреләр, бергә булганда гына, уңышка ирешә алулары турында сүз бара. Әгәр дә бүре, үзе генә булса, ул куркып китәргә дә мөмкин. Ялгыз булганда, ул көчсез була, һәм кешегә ташлана алмый. (19) җөмләдә бүре беркемгә дә ялагайланмый, шулай ук кешене дә ярарга тырышмый.

Шулай итеп, мин нәтиҗә ясый алам. Бүреләр - алар куркыныч җәнлекләр. Шуның өчен алардан сак булырга һәм еракта йөрергә кирәк.

„Ә бүре беркемгә дә ялагайланмый, ярарга тырышмый. Бәлки кеше шуңа күрә дә аны дошман күрәдер." Мин Ф. Фәтхелислам сүзләре белән ризалашам һәм, шуны расларга, ике дәлил китерермен.

Беренче абзацта автор „цирк хайваннары" турында сөйли: „аю да кешеләр өчен бии, авыр сөякле фил дә тамашачыларга карап тезләнә, куркыныч булып тоелган арысланнар, юлбарыслар да, тешләрен ыржайтып, әмер үтиләр." Әмма бүре андый түгел. Ул бик горур һәм буйсынмый торган җәнлек.

16 җөмләдә Ф. Фәтхелислам, кешене авырлыктан кача, җиңеллеккә ашкына, ди. Ә бүре ялагайланмый, ярарга тырышмый.

Бәлки ни өчен кеше бүрегә дошман күрә микән? Бер яктан карасаң, бүре - ул бик куркыныч хайван һәм кешегә бик күп җафа китерә ала. Ә икенче яктан карасаң, кеше бүрегә көнләшә. Ни өчен? Бүре буйсынмый, ә кеше икенче кешегә бәйле! Шулай, Фирдүс Фәтхелислам дөрес әйткән.

При недостатке места для ответа используйте оборотную сторону бланка.